ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
“ ТҮБӘН КОНДРАТА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ”
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ
КАРАРЫ

"24 " сентябрь 2018 г. № 49/1

Чистай муниципаль районы
Түбән Кондрата авыл җирлеге
территориясендә гражданнарга
үзара салым кертү һәм аның акчасын
файдалану мәсьәләсе буенча
җирле референдум билгеләү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Жирле референдум турында” 2004 елның 25 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Чистай муниципаль районы “Түбән Кондрата авыл җирлеге” Уставының 11 статьясы нигезендә, Түбән Кондрата авыл җирлеге Советының “Референдум үткәрү инициативасы турында” 2018 елның 20 сентябрендәге 48/1 номерлы карары, Түбән Кондрата авыл җирлеге Башкарма комитетының “Референдум үткәрү инициативасы турында” 2018 елның 20 сентябрендәге 15 номерлы карары белән, Түбән Кондрата муниципаль берәмлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Чистай муниципаль районы Түбән Кондрата авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумны 2018 елның 18 ноябренә билгеләргә.
2. Җирле референдумга кертелә торган түбәндәге мәсьәләләрне расларга:
   1) “Сез Чистай муниципаль районы Түбән Кондрата авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2019 елда 150 сум күләмендә үзара салым салуны кертүгә һәм җыелган салым акчаларын түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә ризамы :

- Түбән Кондрата авылында эчке сууткәргеч челтәренә ремонт ясауга һәм янгынга каршы гидрантлар сатып алуга һәм аларны урнаштыруга;

ӘЙЕ ЮК”.

2) Сез 2017 елда кертелгән мәсьәлә буенча: Түбән Кондрата авылында гидротехник корылмага капиталь ремонт ясау өчен проект-смета документы әзерләүгә ( 20 400сум халыктан җыелган акча, 81 600 сум Рсеппубликадан күчкән акча) һәм 2018елда кертелгән мәсьәлә буенча: Түбән Кондрата авылында гидротехник корылмага капиталь ремонт ясау өчен проект-смета документы әзерләүгә ( 1000 сум халыктан җыелган акча, 4000 сум Республикадан күчкән акча) җыелганнан калган салым акчаларын түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә ризамы:

Авыл эчендәге юлларны ремонтлауга.

ӘЙЕ ЮК”.

3. Әлеге карарны Чистай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрдә, авыл җирлегенең халык күпләп җыела торган урыннарга, мәгълүмат стендлары һәм такталарына урнаштырырга.

Түбән Кондрата авыл җирлеге
башлыгы С. В. Васильев